РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

21.10.2020 | № 1407-п

“2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районының муниципаль
милке белән идарә итү” муниципаль
программасын раслау турында

РФ Бюджет кодексының 184.1 статьясының 3.1 пунктын үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. “2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль милке белән идарә итү” муниципаль программасын (алга таба - Программа) расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе А.М. Галиуллинга йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы М.Р. Ишниязов

Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 21 октябрендәге
1407-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**“2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль милке белән идарә итү” муниципаль программасы**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль милке белән идарә итү” (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләүче | Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итүнең максималь нәтиҗәлелеген, аның керемлелеген һәм сакланышын тәэмин итү. |
| Программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль милкен һәм җир кишәрлекләрен тулы һәм төгәл исәпкә алуны тәэмин итү.<br>2. Муниципаль милек һәм җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле эш итү һәм алардан файдалануны тәэмин итү. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2021-2025 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | Ярдәмче программалар каралмаган |
| Программаны финанслау күләмнәре | 1 кушымта нигезендә 2021-2025 елларда Программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 9 482,262 мең сум тәшкил итә , шул исәптән:<br>2021 елда - 1 895,203 мең сум;<br>2022 елда - 1 896,089 мең сум;<br>2023 елда - 1 896,990 мең сум;<br>2024 елда - 1 896,990 мең сум;<br>2025 елда - 1 896,990 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |
| Программаның соңгы көтелгән нәтиҗәләре | - җирле бюджетның керем өлешен тулыландыру;<br>-салым булмаган керемнәрне рациональ администрацияләү;<br>- муниципаль мөлкәтне исәпкә алуны оптимальләштерү; |

| | |
|---|---|
| | -мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен арендага алган өчен бурычларны түләтү буенча дәгъвалау эшен арттыру;<br>--муниципаль милек белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә бюджетның салым булмаган керемнәрен арттыру (аукцион сатулары аша сату). |

## 1. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, күрсәтелгән өлкәдәге төп проблемаларны тасвирлау һәм аның үсеш фаразы

Саба муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль милектә булган җир кишәрлекләре белән һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү гамәлгә ашырыла.

Җир кишәрлекләренә карата җир кишәрлекләрен арендага, милеккә, түләүсез вакытлы файдалануга, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карарлар кабул ителә, арендага, түләүсез файдалануга, сату-алуга шартнамәләр төзелә, алар җир кишәрлекләренә ия булу яисә аннан файдалану хокукларының көчүен күздә тота. Югарыда күрсәтелгән шартнамәләрне төзү тәртибенең үзенчәлекләре Россия Федерациясе Җир кодексы белән билгеләнә.

2019 елда Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан гомуми мәйданы 115,45 кв. метр булган 297 җир кишәрлеге бирелгән, шул исәптән:

- гомуми мәйданы 51,57 га булган 164 җир кишәрлеге арендага;
- гомуми мәйданы 63,88 га булган 133 җир кишәрлеге милеккә;

Арендага бирелгән 164 җир кишәрлегенең:

- гомуми мәйданы 7,01 гектар булган 39 җир кишәрлеге шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә бирелгән;
- гомуми мәйданы 13,75 га булган 47 җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясы нигезендә ачык аукционда бирелгән;
- гомуми мәйданы 24,96 га булган 19 җир кишәрлеге РФ Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен бирелгән;
- гомуми мәйданы 5,85 га булган 59 җир кишәрлеге башка максатлар өчен бирелгән (гаражлар, җитештерү эшчәнлеге, сәүдә эшчәнлеге һ.б.).

Милеккә бирелгән 133 җир кишәрлегеннән:

- гомуми мәйданы 5,61 га булган 53 җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 ст.6 п.2 п.п., 39.20 ст.1 п., “Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” Федераль закон нигезендә шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән ;
- гомуми мәйданы 1,09 га булган 15 җир кишәрлеге башка максатлар (гаражлар, сәүдә объектлары) өчен Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 п.2 п.п., 39.20 ст.1 п., “Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” Федераль закон нигезендә бирелгән;
- гомуми мәйданы 1,02 гектар булган 9 җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясы һәм “Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” Федераль закон нигезендә шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән;
- гомуми мәйданы 56,00 га булган 56 җир кишәрлеге шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен күпбалалы гаиләләргә Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 $^{1}$ статьясы нигезендә бирелде.

Саба муниципаль районында Татарстан Республикасы Җир кодексының 32$^{1}$ статьясы гамәлгә керә башлаганнан бирле күпбалалы гаиләләргә шәхси торак төзелеше

һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен барлыгы гомуми мәйданы 82,76 га булган 827 җир кишәрлеге бирелгән.

## 2. Программаны гамәлгә ашыруның төп максатлары һәм бурычлары, сроклары һәм этаплары

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итүнең максималь нәтиҗәлелеген, аның керемлелеген һәм сакланышын тәэмин итү.

Программаның бурычлары:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль милкен һәм җир кишәрлекләрен тулы һәм төгәл исәпкә алуны тәэмин итү.
2. Муниципаль милек һәм җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле эш итү һәм алардан файдалануны тәэмин итү.

## 3. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

1 кушымта нигезендә 2021-2025 елларда Программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 9 482,262 мең сум тәшкил итә , шул исәптән:

2021 елда - 1 895,203 мең сум;
2022 елда - 1 896,089 мең сум;
2023 елда - 1 896,990 мең сум;
2024 елда - 1 896,990 мең сум;
2025 елда - 1 896,990 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

## 4. Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре

Программа чараларын гамәлгә ашырудан турыдан-туры икътисадый файда түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- җирле бюджетның керем өлешен тулыландыру;
- салым булмаган керемнәрне рациональ администрацияләү;
- муниципаль мөлкәтне исәпкә алуны оптимальләштерү;
- мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен арендага алган өчен бурычларны алу буенча дәгъвалау эшен көчәйтү;
- муниципаль милек белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә бюджетның салым булмаган керемнәрен арттыру (мөлкәтне аукцион сатулар юлы белән сату).

Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020
елның 21 октябрендәге 1407-п
номерлы карарына 1 кушымта

**“2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү” муниципаль программасы**

| Программаның исеме | Башкаручы | Финанслау чыганагы | Программаны гамәлгә ашыруга акча күләме, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | БАРЛЫГЫ | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| “2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль милке белән идарә итү” | Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | Муниципаль бюджет | 9 482,262 | 1 895,203 | 1 896,089 | 1 896,990 | 1 896,990 | 1 896,990 |